ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАТАР ЯМАЛЫ АВЫЛ
ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

423753, Татар Ямалы авылы,
Ленин ур.,6 нчы йорт.
Тел/факс 5-75-19

СОВЕТ ТАТАРСКО-
ЯМАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423753, село Татарские Ямалы,
ул.Ленина,дом 6.
Тел/факс 5-75-19

**КАРАР**
**17 .09.2019**

**РЕШЕНИЕ**
**№24**

## Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел,№ 67-ФЗ “Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында” Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, “Җирле референдум турында” 2004 елның 24 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12, 17 статьялары, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының “Татар Ямалы авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, Актаныш муниципаль районы Татар Ямалы авыл җирлеге Советы

**Карар чыгарды:**

1. Түбәндәге мәсьәлә буенча җирле референдум үткәрүне инициировать итергә:

"2020 елда 18 яшькә җиткән, яшәү урыны җирлек чикләрендә теркәлгән һәр гражданнан 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертүгә, аларның җирле референдумда катнашуына һәм тавыш биргәндә белдерелгән мөнәсәбәтләренә бәйсез рәвештә көндезге формада белем алучы студентлар, 1 төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышы ветераны, аларның саны җирлек халкының гомуми саныннан 30 проценттан да артмый, алдагы эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны юнәлтү турында:

Күмү урыннарын карап тору;

Автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге:

- юлларны формалаштыру һәм тигезләү,ком һәм таш салу, грейдер белән тигезләү, кышкы юлларны карау, юл билгеләре кую.

Җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру;

Оешма чикләрендә халыкны су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу;

Җирлек халкының массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру;

**“ӘЙЕ “** **“ЮК”**

2. Әлеге карар махсус мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча урнаштырылган: ТР, Актаныш муниципаль районы, Татар Ямалы авылы, Ленина ур., 6 йорт, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмати порталында һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Татар Ямалы авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштыр.

3. Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Авыл җирлеге башлыгы Д.Ф.Валиев